**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 5 февралендәге 261 номерлы карары**

**Казан шәһәренең Мәскәү районында ачык сервитут билгеләү турында**

1. Әлеге карарның 1, 2, 3, 4 номерлы кушымталары нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган ачык сервитут характеристикасы:

- ЗУ 1 йогынты ясала торган мәйдан – 3 кв.м;
- үзенә карата хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры – 16:50:0000:30569;
- ЗУ 2 йогынты ясала торган мәйдан – 59 кв.м;
- үзенә карата хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры – 16:50:0000:7015;
- урнашу урыны: Казан шәһәре, Мәскәү районы;
- билгеләү максаты: суүткәргеч челтәрләр төзү;
- билгеләү вакыты: 1 ел;

1.2. мөрәҗәгать итүче: «ТГК-16» акционерлык җәмгыяте;

1.3. билгеләү нигезләре: гариза бирүче мөрәҗәгате, Россия Федерациясе Җир кодексының V.7 бүлеге, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясы, Казан шәһәре Думасының 2020 елның 28 февралендәге 5-38 номерлы карары белән расланган Казан шәһәр округының Генераль планы, «Елга суын үткәргеч. ВВ-34, ВВ-35 ябу җайланмаларыннан алып КТЦ Казан ТЭЦ-3 төп корпусына кадәр елга суын чыгару торбаларын төзү» объектына 23-0321/2023 номерлы проект документлары.

2. «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарның 1, 2, 3, 4 номерлы кушымталары нигезендәге чикләрдә ачык сервитутның гамәлдә булу өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү һәм ачык сервитутны дәүләт теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр

һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итүне йөкләргә.

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән ачык сервитут өчен түләү Россия Федерациясе Җир кодексының 39.46 статьясындагы 2, 3, 4, 5, 7 һәм 8 пунктлар нигезендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның 2 һәм 4 номерлы кушымтасыннан кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

6. «ТГК-16» акционерлык җәмгыятенә әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән җир кишәрлекләрен, урнаштыру өчен ачык сервитут билгеләнгән инженерлык корылмасын төзү, капиталь яки агымдагы ремонтлау, реконструкцияләү, эксплуатацияләү, консервацияләү, сүтү эшләре тәмамланганнан соң яисә Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясындагы 2, 5 пунктлар белән каралган максатларда ачык сервитут билгеләнгән очракларда – җир кишәрлегендә тәэмин итү өчен ачык сервитут билгеләнгән эшчәнлек тәмамланганнан соң өч айдан да соңга калмыйча, алардан рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану өчен яраклы хәлгә китерергә тәкъдим итәргә.


7. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 17 декабрендәге 5202 номерлы «Казан шәһәренең Мәскәү районында ачык сервитут билгеләү турында»гы карарын гамәлдән чыккан дип танырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 5 февралендәге
261 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Казан шәһәренең Мәскәү районында ачык сервитут йогынты ясый торган өлкә чикләре**





Масштаб 1:100
Координаталар системасы: МСК-16

| Шартлы билгеләр: | |
|---|---|
| 1 | яңа ясалган характерлы нокта |

| | |
|---|---|
| | билгеләнә торган сервитут чиге |
| | гамәлдәге җир кишәрлекләренең чиге |
| | территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналар (гамәлдәге) |
| | кызыл линияләр (гамәлдәге) |
| | капиталь төзелеш объектлары (мәйданлы) |
| 16:50:000000 | кадастр кварталы |
| 16:50:000000:30569 | үзенә карата хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры |

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 5 февралендәге
261 номерлы карарына
3 номерлы кушымта

**Казан шәһәренең Мәскәү районында ачык сервитут йогынты ясый торган өлкә чикләре**




Масштаб: 1:100
Координаталар системасы: МСК-16

Шартлы билгеләр:

| | |
|---|---|
| | Сервитутлар (статуссыз) |
| | Ясала торган җир кишәрлекләре чикләре (гамәлдәге) |
| | Җир кишәрлекләре |
| 16:50:000000 | кадастр кварталы |
| 16:50:000000:7015 | үзенә карата хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең |